КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 21 март г.Казань № б-601

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 17 август, б-1012 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 8 апрель, б-490 нчы; 2013 ел, 27 май, б-911 нче; 2014 ел, 10 март, б-463 нче; 2015 ел, 4 июнь, б-1175 нче; 2017 ел, 17 гыйнвар, б-50 нче; 2017 ел, 16 июнь, б-1312 нче; 2018 ел, 26 апрель, б-982 нче; 2020 ел, 5 август, б-1484 нче; 2023 ел, 24 февраль, б-494 нче; 2023 ел, 25 март, б-749 нчы; 2025 ел, 22 гыйнвар, б-65 нче; 2025 ел, 31 гыйнвар, б-187 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инвалидларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны һөнәри әзерләү һәм эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне.»;

3 пунктта «ел саен» сүзләреннән соң «, 1 майга кадәр,» сүзләрен өстәргә;

Инвалидларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны һөнәри әзерләү һәм эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне (боерыкка теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2009 ел, 17 август, б-1012 нче
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 21 март, б-601 нче
карары редакциясендә)

# Инвалидларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны һөнәри әзерләү һәм эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Инвалидларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны һөнәри әзерләү һәм эш белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – ведомствоара эшче төркем) инвалид балаларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның һөнәри укуга һәм һөнәри белем алуга хокукларын, шул исәптән һөнәри белем бирү оешмаларында инвалид балаларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга белем алу өчен махсус шартлар тудыру юлы белән тормышка ашыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында төзелде.

1.2. Ведомствоара эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

## II. Ведомствоара эшче төркем бурычлары

2.1. Ведомствоара эшче төркем бурычлары:

инвалид балаларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның һөнәри укуга һәм һөнәри белем алуга хокукларын, шул исәптән Татарстан Республикасындагы һөнәри белем бирү оешмаларында инвалид балаларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларга белем алу өчен махсус шартлар тудыру юлы белән тормышка ашыру мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары, эш бирүчеләр эшчәнлеген координацияләү;

Татарстан Республикасындагы һөнәри белем бирү оешмаларында инвалид балаларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның һөнәри укуга һәм һөнәри белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча килешенгән карарлар әзерләү;

Татарстан Республикасындагы һөнәри белем бирү оешмаларында инвалид балаларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның һөнәри укуга һәм һөнәри белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру механизмнарын

камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр эшләү;

инвалид балаларны һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны укыту (шул исәптән электрон белем һәм дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып) өчен белгечлекләр, һөнәрләр спектрын арттыру.

III. Ведомствоара эшче төркем эшчәнлегенең тәртибе

3.1. Ведомствоара эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма елга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

3.2. Ведомствоара эшче төркем рәисе ведомствоара эшче төркем әгъзаларының читтән торып тавыш бирү юлы белән ведомствоара эшче төркем утырышын читтән торып уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

3.3. Ведомствоара эшче төркем әгъзаларының читтән торып тавыш бирү юлы белән ведомствоара эшче төркем утырышын читтән торып уздыру турында карар кабул ителгәндә, ведомствоара эшче төркем секретаре, ведомствоара эшче төркем утырышын уздыру көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, ведомствоара эшче төркем әгъзаларына утырышның көн тәртибен һәм читтәр торып тавыш бирүгә чыгарылган һәр мәсьәлә буенча ведомствоара эшче төркем рәисенә язма рәвештә бирү сроклары турындагы мәгълүматны җиткерә.

3.4. Ведомствоара эшче төркем әгъзалары ведомствоара эшче төркем утырышында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

3.5. Ведомствоара эшче төркем әгъзалары шәхсән тавыш бирәләр. Аларга үз вәкаләтләрен башка затларга бирү рөхсәт ителми.

3.6. Ведомствоара эшче төркем утырышы, әгәр анда исемлектә бирелгән әгъзалар составының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

3.7. Ведомствоара эшче төркем киңәшләре аның әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, ведомствоара эшче төркем утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.8. Ведомствоара эшче төркем тәкъдимнәре беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа ведомствоара эшче төркем утырышында рәислек итүченең имзасы куела.

3.9. Ведомствоара эшче төркем утырышының беркетмәсе ведомствоара эшче төркем секретаре тарафыннан ведомствоара эшче төркем утырышы үткәрелгән көннән 10 эш көне эчендә ведомство буйсынуындагы оешмалар белән эшләүне оештыру өчен ведомствоара эшче төркем әгъзаларына җибәрелә.

_______________________